РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЙБИЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЙБЫЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 ноябрь 2022 ел № 24

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Указы нигезендә, Кайбыч авыл җирлеге Уставына таянып, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән Кайбыч авылының 2022 елның 02 ноябрендәге 1 номерлы, Югары Наратбаш авылының 2022 елның 03 ноябрендәге 1 номерлы, Кыр Әнәле авылының 2022 елның 04 ноябрендәге 1 номерлы карарларын тормышка ашыру максатларында Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктына киләсе редакциядә 2нче абзацны өстәргә:

«Үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә:

- Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, шулай ук мобилизацияләнүче белән бергә яисә аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын;

- Украинадагы махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрбиләр, шулай мобилизацияләнүче белән бергә яки аннан аерым яшәгән гаилә әгъзаларын;

- Украинада махсус хәрби операция зонасында булган волонтерлар, шулай ук мобилизацияләнүче белән бергә яки аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын.»

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 22 ноябрендә 15 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru

адресы буенча бастырып чыгарырга һәм ТР, Буа районы, Кайбыч авылы, Тынычлык урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.И. Нуретдинова